# Туган як тарихы битләре


- **Ниязова Дарина Дамир кызы**
- **Исәт урта мәктәбе Ялутор районы**


**13 апреля 2017 г.**

# Минем илем- Рәссәй (Россия)




# Башкала- Мәскәү (Царицыно утары)



# Безнең президентыбыз-Владимир Владимир улы Путин




# Төмән өлкәсе



# Төмән өлкәсе губернаторыбыз- Владимир Владимир улы Якушев




# Рәссәй Себер иле белән баер!




# Ялутор- декабристлар шәһәре




# Декабрист И.Д. Якушкин һәм М.И. Муравьев-Апостол йортлары.






Җитәмени безнең туган якка.
Җәен - яңгыр, кышын - кар исен
Күкрәгеңә сулап, биек таудан
Ил киңлеген сөенеп карыйсың.
Сандугачлар кайтып моңнар түгә,
Канат кага күктә бөркетләр.
Көзен бөтен җиргә муллык җәя
Язын чәчкән энҗе бөртекләр.
*Нур Гайсин*




**Дәүләтебез – гөлчәчәкле Рәссәй. Өлкәбез -Төмән өлкәсе. Ә инде туган авылым Исәт- Төмән өлкәсенең кечкенә бер өлешен тәшкил итә. Төмән картасында ул бер нокта гына булып күренсә дә, туган авылым минем өчен иң зур, иң кадерле җир булып тоела. Туган җир... Туган авыл...**

**Йөрәккә нинди якын һәм кадерле бу сүзләр. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, туган авылы бар. Туган авылымның  һәр сукмагы, һәр агачы,аның барча кешеләре күңелгә бик тә якын.**

- Кемгә ничектер, ә минем өчем, доньяда иң матур авылларының берсе ул Исәт авылы. Йортлары төзек, урамнары киң, иркен, койма-капкалары матур бизәлгән, буялган. Ул табигатьнең бик матур җиренә урнашкан. Авыл читеннән талгын гына Исәт елгасы ага. Елга буе агачлыкка төренгән. Тирә-ягын «Ак курас» биләп тора. Ә иген басуларын күрсәң шаккатырсың - диңгез кебек дулкынланып, тирбәлеп тора.






Хәзерге вакытта исәттә 600 кеше яши. Авылымның  урам исемнәре бераз кызыклы булса да, санап үтәм: «Яр», «Мәктәп», «Механизатор», «Төнъяк» , Габдулла Тукай һәм Марат Мулюков урамнары, Югары оч, Уртак оч. Мин үзем  халык теле белән әйткәндә Габдулла Тукай урамында яшим. Мәктәп тә якында гына, мәдәният йорты, кибетләр дә өебездән ерак түгел. Авылымның гүзәл кешеләре, кызыклы тарихы да бар. Мәктәбебездә туган якны өйрәнү музее эшли. Анда  туган җирем турында материал тупланган. Авылның беренче кешеләре белән беррәттән, аның бүгенге көндә танылган шәхесләре турында мәгълүмат та  бар биредә.





# “Механизаторлар” урамы







Минем уемча, һәр авыл җир йөзендәге меңләгән авыллар арасыннан кайсыдыр ягы белән аерылып тора. Нинди дә булса үзенә генә хас сыйфаты, күренекле кешеләре, табигате, тарихы була аның. Җир йөзендә һәр нәрсә эз калдырган кебек, Ватаныбыз тарихында минем дә туган авылымның өлеше бардыр, минемчә. Чөнки кечкенә генә чүлмәк кисәге дә, сакланып калган иске йортлары да гасырлар авазын саклый. Авылларда безнең татар халкының моңы, кайгы-шатлыгы яшеренгән.




1922 елда Исәт елгасының төньяк ярында, иске мәчет өендә ике бүлмәле мәктәб ачылды. 1932 елда мәчет янды һәм авылга мәктәб урынына таш өй бирелде. 1936 елда 7-еллык мәктәб ачыла. Беренче директор Мулюков Абдрасул абый була. 1999 елда Макарова Айсылу Нургали кызы җитәкчелегндә 11- еллык мәктәб ачыла





Безнең авылда яңа, матур мәчет 2006 елның 11 августында төзелде. Авыл халкыбыз динле, олысы да кечесе дә мәчеткә йөри.



- Авылыбызда халык бәйрәмнәре, йолалары үткәрелеп тора. Алар арасында елның төрле вакытларына бәйле: боз озату, ботка бәйрәме, Нәүрүз, Нардуган, каз өмәсе, Сабан туе, бәби туе, өй туе.
- Дини бәйрәмнәрне дә олылап уткәреп киләбез: Ураза гаете, Корбан гаете, Мәүлид бәйрәме.









**Бөек Ватан сугышы авылымның кайгылы һәм героик бите. Сугышка бер- бер артлы 112 кеше китә. Илебезнең төрле якларында сугышкан минем авылдашларым төрле медаль, орден, грамоталар белән бүләкләнәләр. 4 кешебез Кызыл Йолдыз Кавалер ордены белән бүләкләнә. 65 кешебез туган якка кире кайтмый,сугыш кырларында батырларча һәлак булалар. Сез һәрвакыт безнең күңелдә!**











# Игътибарыгызга рәхмәт